РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Микулинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. Советская, д. 74, Азнакаевский район,
с.Микулино, 423306,
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
башкарма комитеты

Советская ур., 74 йорт, Азнакай районы,
Микулино авылы, 423306
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «25»10.2022г.** **№20**

2021 елның 14 декабрендәге 29 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1601 статьясындагы 32 пунктының өченче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елның 14 декабрендәге 29 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе» 292 бүлекне түбәндәге эчтәлекле юллар белән тулыландырырыга:

| | | |
|---|---|---|
| «292 | 2 02 25576 10 0000 150 | Авыл территорияләрен комплекслы үстерүне тәэмин итүгә авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр |
| 292 | 2 02 29999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына башка субсидияләр |
| 292 | 208 10000 10 0000 150 | Түләүләр башкару өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (авыл җирлекләре бюджетларына) акча күчерү |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Азнакай муниципаль районы сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык И.А.Такиулин